СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.06.2020 г. Заинск № 184

**«Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре милкендәге, өченче затлар хокукларыннан азат булган (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга озак сроклы файдалануга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеге турында» Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының 2017 елның 15 ноябрендәге 92 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы 4.1 өлеше, «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне киңәйтү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре милкендәге, өченче затлар хокукларыннан азат булган (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга озак сроклы файдалануга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеге турында» Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының 2017 елның 15 ноябрендәге 92 номерлы карарына 1нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, икътисадый үсеш һәм муниципаль милек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**

Зәй муниципаль районы
Зәй шәһәре Советының
«_03_» _06_ 2020 ел
_184_ номерлы карарына
1нче кушымта

**Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре милкендәге, өченче затлар хокукларыннан азат булган (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга озак сроклы файдалануга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт**

**ИСЕМЛЕГЕ**

| № п/п | Мөлкәтнең исеме | Гомуми мәйданы, кв.м | Урнашу урыны, адресы | Бинаның билгеләнеше/җир кишәрлегенең категориясе | Кадастр номеры |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Гараж | 73,4 | ТР, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., «Энергетик-2» гараж ширкәте, №168 | Торак булмаган бина | 16:48:070104:2546 |
| 2 | Гараж | 144 | ТР, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., «Энергетик-2» гараж ширкәте | Торак булмаган бина | 16:19:070104:2582 |